**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР

2020 елның 14 феврале № 268

Бишнә авыл җирлеге Советының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыюны оештыру турында"гы 2011 елнын 10 ноябрендәге 37 нче карары һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Бишнә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яктырту җайланмаларын, электр лампаларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең яңа редакциясен раслау турында"гы 2014 елнын 4 апрелендәге 156 нчы карары үз көчен югалткан дип санау хакында

Казан районара табигать саклау прокуратурасының 5.02.2020 ел, 02-07-2020-20 һәм 02-07-2020-21 номерлы федераль законнарга каршы килә торган норматив-хокукый актларына протестлары нигезендә, Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы карарлары үз көчен югалткан дип тану:

- «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыюны оештыру турында" 2011 елнын 10 ноябрендәге 37 нче карары;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Бишнә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яктырту җайланмаларын, электр лампаларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең яңа редакциясен раслау турындагы» 2014 елның 4 апрелендәге 156 номерлы карары».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составында Зеленодольск муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» информацион телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы).

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**